| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 11.02.2022 г. Казань № 36/2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 20 октябрендәге 284 санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршындагы иҗтимагый шура турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый шура турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 санлы карары белән расланган Татарстан Республиасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый шура турында бер төр нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 54 санлы карары нигезендә
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 20 октябрендәге 284 санлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 31 маендагы 142 санлы, 2021 елның 20 ноябрендәге 731/2021 санлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршындагы иҗтимагый шура турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлектә:

6.6 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Дәүләт комитеты рәисенең Иҗтимагый шура әгъзасы вәкаләтләрен туктатып тору турындагы карары Дәүләт комитеты боерыгы белән әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда расланырга тиеш.»;

6.7 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Дәүләт комитеты рәисенең Иҗтимагый шура әгъзасы вәкаләтләрен туктату турындагы карары Дәүләт комитеты боерыгы белән әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда расланырга тиеш.»;

6.8 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Дәүләт комитеты рәисенең Иҗтимагый шура әгъзасы вәкаләтләрен яңартып җибәрү турындагы карары Дәүләт комитеты боерыгы белән әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда расланырга тиеш.».

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина